**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әсәй авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Әсәй авылы № 42 25.10.2016 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының 2016 елның 14 июнендәге 33 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмә хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында "Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 2016 елның 03 июлендәге 366-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү өчен

Әсәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының 2016 елның 14 июнендәге 33 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмә хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 бүлекнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планына (программасына) кертелгән унитар предприятиеләр, акционер җәмгыятьләр һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр Башкарма комитетка аның мәҗбүри нөсхәсен тапшыру өчен бухгалтерлык исәбе турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокта еллык бухгалтерлык (финанс) хисабын, квартал өчен аралык бухгалтерлык (финанс) хисабын, ярты ел, тугыз ай - күрсәтелгән хисаплылыктагы мәгълүматны «Интернет» челтәрендәге Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән сайтка хисап чоры тәмамланганнан соң утыз көннән дә соңга калмыйча - www.rosim.ru, һәм өстәмә рәвештә Азнакай муниципаль районының «Интернет " челтәрендәге рәсми сайтында - http://aznakayevo.tatarstan.ru (алга таба - «Интернет»челтәрендәге сайтлар) урнаштырырга.

1.2. 9 бүлекнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.Муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы), муниципаль мөлкәт милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруны планлаштыру актлары, муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарлар, муниципаль мөлкәтне сату турындагы һәм аны сату йомгаклары турындагы мәгълүмати хәбәрләр, муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру нәтиҗәләре турындагы хисаплар «Интернет»челтәре сайтларында урнаштырылырга тиеш.».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис Л.М. Вәлиева